

ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК ,ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

№2 Ноябрь Декабрь
2021 нче ел

# МӘКТӘП СУЛЫШЫ

## Бу санда

*Әниләр көне*




*Ләбиб Леронга -60 яшь*



*Татар теле һәм әдәбияты укытучылары семинары*




**Ана-Бөек исем,**
**Нәрсә җитә ана булуга;**
**Хатыннарның бөтен матурлыгы;**
**Бөтен күрке ана булуда......(Һ.Такташ)**

Бу дөньяда тиңе булмаган, беркемне дә битараф калдырмый торган һәм барыбыз өчен дә кадерле бәйрәм бар. Ул-Әниләр көне. Ноябрьнең соңгы атнасында билгеләнә торган әлеге бәйрәм мәктәбебездә ел да олылап уздырыла. Укучылар кадерле әниләренә үз куллары белән бүләкләр ясыйлар, шигырьләр, җырлар өйрәнәләр, видео котлаулар әзерлиләр. Быелгысы да матур мизгелләр белән хәтердә калды.

Без үз тормышыбызны әниләрдән башка күз алдына китерә алмыйбыз. Алар-дөньябызның яме. Алар-иң газиз, якын кешеләребез. Ул безне тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, беренче елмаюбызны, беренче әйткән сүзләребезне ишетеп сөенгән, тәпи атлап китүебезне күреп шатланган. Әниләр мәхәббәте безне ышанычлырак һәм көчлерәк булырга, авырлыкларны җиңәргә, уңышка ирешергә ярдәм итә.

Ихлас күңелдән сезгә исәнлек, күңел тынычлыгы, гаилә җылылыгы телибез. Сезгә иң матур теләкләр әйтелсен, балаларыгыз һәрвакытта да уңышлары белән куандырсыннар һәм ярату бүләк итсеннәр!



# Татар теле һәм әдәбияты укытучылары семинары

26 нчы ноябрь көнне мәктәбебездә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының “ Яңа буын ФГОСка күчү шартларында рус телле балаларга татар теле һәм әдәбияты дәресләренең предмет нәтиҗәсе һәм аларга ирешү юллары” темасына гамәли-юнәлешле семинар үтте. Семинарда Татарстанның атказанган укытучысы, педагогия фәннәре кандидаты, халык мәгарифе отличнигы Хәйдарова Роза Зәки кызы катнашты. Хәйдарова Роза Зәки кызы дәреслеге белән укытучы татар теле һәм әдәбияты укытучысы Юсупова Руфина Рим кызы ачык дәрес күрсәтте. Семинарның гамәли өлешен Роза Зәки кызы алып барды. Районыбызның татар теле укытучылары кирәкле мәгълүматлар алдылар.











**Тәмле булсын**

***Бүген бәйрәм табынына кош теле әзерлибез.Кош теле** – татар халкының табын күрке булган милли ризыкларының берсе.*

**Кош теле:**

**Камыр ясау өчен:** 1,5 стакан он, 5 йомырка, бер чеметем шикәр комы, өстенә сибәр өчен шикәр оны, бераз чәй содасы, кыздырыр өчен он.





Савытка йомырка сытарга, шикәр комы, чәй содасы өстәргә һәм шикәр эреп беткәнче болгатырга. Аннары он салып, камыр басабыз. Камырны 1-1,5 мм калынлыкта җәяргә һәм махсус тәгәрмәч белән 3-3,5 см киңлектәге тасмаларга кисәргә. Тасмаларны 4-5 см лы кыек шакмаклар рәвешендә турап, кайнап торган сары майга салып пешереп алырга. Суытып, шикәр оны сибеп, вазаларга салып, табынга чыгарырга.





***Бәйрәм сыебыз әзер! Ашларыгыз тәмле булсын!***



*Бүген бездә кунакта*

# *Татар язучысы, шагыйрь, журналист Ләбиб Леронга 60 яшь*



Ләбиб Лерон (Лемон Лерон улы Леронов) 1961 елның 11 ноябрендә Татарстан Республикасының Мөслим районы Түреш авылында дөньяга килә. Бала чагы Актаныш районының Олыймән авылында уза. 1979-1984 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. Университетта укыган елларында ук (1983) «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә эшли башлый. 1986–1988 елларда Татарстан Язучылар берлегендә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры вазифасын башкара.

1989–2011 елларда «Салават күпере» журналы редакциясендә – әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 2011–2012 елларда – «Казан утлары» журналы редакциясендә, 2012–2013 елларда – «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә бүлек мөхәррире вазифаларын башкара. 2013 елның 30 декабреннән исә – «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире.

Ләбиб Лерон әдәбиятның төрле жанрларында балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә бердәй актив яза. Ул – балалар өчен «Яңгырның ял көне» (1988) дигән шигырьләр җыентыгы, «Транзистор үч ала» (1989) дигән шаян хикәяләр, «Тәгәрмәчле чана» (1993) дигән әкиятләр, «Таһир маҗаралары» (2000) дигән комикс китаплары, «Кояшны кочкан малай» (2004) дигән шигырьләр, әкиятләр, мәзәкиятләр, җырлар, пьесалар җыентыгы авторы. Өлкән укучылар аны шулай ук сатирик һәм юмористик эпиграммалар, пародияләр («Күрше тавыгы» (2008) һәм «Юморкалар» (2015) җыентыклары), лирик-публицистик шигырьләр («Сине генә сөям» (1997) җыентыгы), «Шайтан шаяруы», «Бәллүр төн» кебек каһкаһәле повесть-хикәяләр авторы буларак та белә.



# *Мәктәп тормышыннан*

**11 нче ноябрь көнне**, 2 нче санлы Урыссу урта мәктәбендә, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге кысаларында, Ләбиб Леронның 60 яшенә багышланган чара үтте. Укучылар язучының хикәяләрен, шигырьләрен искә төшерделәр, “Супермалай” әсәренә аерым тукталдылар. Эш, хезмәт темаларына караган мәкальләрнең мәгънәләрен аңлаттылар, рәсем төшерделәр, кроссворд чиштеләр, тест сорауларына җавап бирделәр.





Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын йомгаклау максатыннан мәктәбебездә “Туган телем-иркә гөлем” исемле чара үткәрелде. Чарада туган телгә багышланган шигырьләр сөйләнде, мәкальләр һәм табышмаклар әйтелде. Татар халык биюләре, җырлары белән үрелеп барылды.





*Ә син белә идеңме?*



## Декабрьгә халык сынамышлары

Декабрьнең егерме бишендә агачларны бәс тотса, алдагы җәй иген уңар.

Декабрьнең утыз берендә төнлә йолдызлар еш күренсә, ашлыклар уңар; шулай ук бәс булса да, ашлыклар уңар.

Декабрьдә кар аз булса, җәй коры килә.

Декабрьдә кара каргалар күренә икән, кыш җылы була.

Карсыз декабрь — коры яз билгесе.

Декабрь башында көчле бураннар, кар яуса, июнь башында яңгырлар була.

Декабрь җилле икән, март җылы була.

Декабрь җылы булса, кыш озакка сузыла, яз салкын була, соңара.

Декабрьгә җир туңса, кар көртләрез булса, уңыш уңа.

1 декабрь – әгәр кышның беренче көнендә кара карга күрсәгез, кыш җылы булыр.

2 декабрь – аяз һава кышның салкын килүе турында сөйли. Әгәр бу көнне кар төшсә, гыйнварга кадәр чатнама суыклар көтмәгез.

3 декабрь көнне кар яуса, 3 июньдә көчле яңгыр явар. Әгәр киресенчә булса, җәй иртә килер.

**Гәҗитне басмага әзерләделәр:**

7 нче сыйныф укучылары

Җитәкчеләре: Хөсәенова Л.Т.

***Сездән язмалар көтеп калабыз!***